**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№280**
**23.01.2019**

Башкарма комитетның «Күп фатирлы йорт советы төзүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 2012 елның 23 мартындагы 1467 нче карары үз көчен югалтуны тану турында

Шәһәр Уставының 9 маддәсе, 50 маддәсенең 1 бүлеге, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.21, 5.23 пунктлары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2012 елның 28 мартында «Челнинские известия» газетасының 24 нче санында басылып чыккан Башкарма комитетның «Күп фатирлы йорт советы төзүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 2012 елның 23 мартындагы 1467 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Ә. Абдуллин